**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

16.11.2022 | № 741

**Физкультура - сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында**

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын календарь планына кертелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» 18.03.2015 ел, № 160 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә (редакциягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп. ТР МКның 26.07.2016 № 509, 21.09.2019 № 868 карарлары) һәм рәсми физкультура чаралары һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын тәртипкә салу максатларында Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга :

- физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын уздырганда спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне тукландыруга чыгымнар нормалары (1 нче кушымта);

-спортчыларны, тренерларны һәм башка физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларында катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Тәтешнең рәсми сайтында бастырырга
һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары
23.05.2016 ел, № 241 «спортчыларны, тренер - укытучыларны, машина йөртүчеләрне, белгечләрне һәм башка физкультура-сәламәтләндерү, спорт, тренировка һәм яшьләр чараларында катнашучыларны азык-төлек һәм яшәү белән тәэмин итүгә чыгымнар нормаларын билгеләү турында» муниципаль районның 23.05.2016 ел, № 241 " үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.В. Николаевага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасимов**